**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында

Моңа кадәр Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырылган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга идарә итү буенча функцияләрне һәм вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына тапшыру белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы структурасын раслау турында» 2011 елның 24 февралендәге ПУ-79 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 3 ноябрендәге ПУ-915 номерлы һәм 2013 елның 30 ноябрендәге ПУ-1169 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 25 март
№ ПУ-368

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «25» мартындагы
368 номерлы Указы белән расланды

# Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы структурасы

